МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

---

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

21.07.2017 № 437

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларны түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак идарә итәргә яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә яллаучы вәкиле рөхсәт итү тәртибе турында

“Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2004 ел 27 июль № 79-ФЗ Федераль законының 17 нче мәкаләсе 1 нче бүлеге 3 нче пунктына карата б о е р а м:

1. Кушылган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларны түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак идарә итәргә яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә яллаучы вәкиле рөхсәт итү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Биредәге боерыкны министр урынбасарларына, министрлыкның структурчыл бүлекләрнең җитәкчеләренә һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.
3. Биредәге боерыкны башкару контролен министр урынбасары О.А. Степущенкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

21 июль 2017 ел № 437
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларны түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак идарә итәргә яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә яллаучы вәкиле рөхсәт итү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларны түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак идарә итәргә яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә яллаучы вәкиле рөхсәт итү тәртибе (алга таба – Тәртип) “Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2004 ел 27 июль № 79-ФЗ Федераль законының 17 нче мәкаләсе 1 нче бүлеге 3 нче пунктына карата төзелгән.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә иҗтимагый оешманы, торак, торак-төзү, гараж кооперативын, бакчачылык, яшелчәлек, дача куллану кооперативын, күчемсез милек хуҗалары ширкәтен (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак идарә итәргә яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә яллаучы вәкиле рөхсәт итү процедурасы белән җайга салына.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы гражданлык хезмәткәрләренә тарала. Алар өчен Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры яллаучы вәкиле булып тора.

2. Түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак коммерциячел булмаган оешмаларны идарә итүдә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә рөхсәт алу турында гаризаны (алга таба – Гариза) биредәге Тәртипнең № 1 кушымтасы буенча язу формасында гражданлык хезмәткәре төзи.

3. Гражданлык хезмәткәре Гаризаны коррупцияле һәм башка җинаятьләр буенча профилактик эш өчен җаваплы шәхескә – Татарстан Республикасы ГТХМ ның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең (коррупциягә каршы эш буенча) җитәкче киңәшчесенә бирә.

4. Җаваплы шәхес Гаризаны аның килү көнендә Журналда әлеге Тәртипнең № 2 кушымтасының формасы буенча терки.

5. Җаваплы шәхес Гаризаның алдан карап тикшерүен башкара һәм аның нәтиҗәләре буенча йомгак хәзерли.

Гаризаны алдан карап тикшерү барышында җаваплы шәхес Гаризаны биргән Татарстан Республикасы ГТХМ ның гражданлык хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешмада планлаштырыла торган идарә итүдә катнашу буенча функцияләрне билгели торган язу аңлатмаларны һәм документларны сорарга хаклы.

Гариза гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак коммерциячел булмаган оешмаларда идарә итүдә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә рөхсәт итү яисә итмәү турында тәкъдимнән торырга тиеш.

6. Гаризаны теркәү көненнән бирле 5 эш көненнән соңга калмыйча гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак коммерциячел булмаган оешмаларда идарә итүдә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә рөхсәт итү яисә итмәү турында карар кабул итәр өчен җаваплы шәхес Йомгакны һәм башка материалларны (булган вакытта) кушып Йомгакны Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрына (аның вазифаларын башкаручы шәхесенә) (алга таба – министр) карап тикшерүгә тапшыра.

Министр (аның вазифаларын башкаручы шәхесе) Гаризаны алу көненнән бирле ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры (аның вазифаларын башкаручы шәхесе) карар кабул итү көненнән бирле җаваплы шәхес гражданлык хезмәткәренә Гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аның кулына кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге мөһере белән расланган министр резолюциясе белән Гариза копиясен бирә. Министр резолюциясе белән Гаризаның оригиналы гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә кушыла.

Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларны түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак идарә итәргә яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә яллаучы вәкиле рөхсәт итү тәртибенең
№ 1 кушымтасы

Татарстан Республикасы ГТХМ министры

________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, урындагы вазифасы һәм структурчыл

________________________________________

бүлекчәсе, тору урыны)

________________________________________

(телефон номеры)

## Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларны түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак идарә итәргә яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә яллаучы вәкиле рөхсәт итү турында гариза

________________________________________________________________________________

(ялгыз хуҗалыкчы башкарма органының яисә коллегиаль идарә итү органының исеме)

буларак түләүсез нигездә _______________________________________________________

(иҗтимагый оешма,

_____________________________________________________________________________________

торак, торак-төзү, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәлек,

_____________________________________________________________________________________

дача куллану коомперативы, күчемсез милек хуҗалары ширкәте исеме)

идарә итүдә катнашырга, коллегиаль идарә итү органының составына керергә (кирәген ассызырга) миңа рөхсәт итәргә үтенәм.

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | __________________ | ______________________________ |
| (дата) | (имза) | (фамилия, инициаллар) |

Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларны түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак идарә итәргә яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә яллаучы вәкиле рөхсәт итү тәртибенең
№ 2 кушымтасы

Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларны түләүсез нигездә ялгыз хуҗалыкчы башкарма органы буларак идарә итәргә яисә аларның коллегиаль идарә итү органнарының составына керергә яллаучы вәкиле рөхсәт итү турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № т/б | Дата | Үтенеч биргәннең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазифасы | Үтенеч биргәннең имзасы | Теркәүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |